**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 гыйнвар № 40

г. Казань

«Казан политехника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белеме бирү учреждениесен аңарга «Казан азык-төлек сәнәгатенең механика-технология техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесен кушу рәвешендә үзгәртеп оештыру турында

Татарстан Республикасының һөнәри белеме бирү оешмалары челтәрен оптимальләштерү, квалификацияле урта звено хезмәткәрләрен һәм белгечләрен әзерләүнең сыйфатын күтәрү, кадрлар әзерләү күләмнәрен арттыру һәм хезмәт ресурсларын тагы да нәтиҗәлерәк файдалану максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Казан политехника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белеме бирү учреждениесен (алга таба – Казан политехника көллияте) аңарга «Казан азык-төлек сәнәгатенең механика-технология техникумы» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесен (алга таба – Казан азык-төлек сәнәгатенең механика-технология техникумы) кушу рәвешендә, Казан политехника көллияте эшчәнлегенең төп максатларын саклап, үзгәртеп оештыру турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә, әлеге максатларга тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында законда каралган акча кысаларында башкарыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Казан политехника көллиятен гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкарырга;

законнарда каралган, бу карарның 1 нче пунктында күздә тотылган учреждениеләрне үзгәртеп оештыру белән бәйле чараларны үткәрүне тәэмин итәргә;

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәп, Казан азык-төлек сәнәгатенең механика-технология техникумы студентларын, ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән, уку-укыту программаларын һәм шартларын саклап, Казан политехника көллиятенә күчерүне тәэмин итәргә;

үзгәртеп оештыру чаралары аркасында эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә законнар нигезендә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә;

бер ай эчендә Казан политехника көллияте уставын эшләргә һәм расларга;

Казан политехника көллияте тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсенә тиешле үзгәрешләрне кертергә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Казан политехника көллияте уставын дәүләт теркәвенә алганнан соң:

60 көн эчендә Казан политехника көллиятенә аның эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәк булган, элек Казан азык-төлек сәнәгатенең механика-технология техникумына оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тапшырган исемлеккә ярашлы рәвештә оператив идарә хокукында билгеләнгән тәртиптә беркетергә;

90 көн эчендә Казан политехника көллиятенә беркетелә торган күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына 2016 елга Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегенә үзгәрешләр кертергә.

6. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, Казан политехника көллияте устав расланганнан соң 60 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларын торак урыннар белән тәэмин итүгә нормативлар чыгымнарны раслау турында» 2015 ел, 16 октябрь, 776 нчы карарына аны бу карарның 1 нче пунктына яраклаштыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында карар проектын әзерләргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\40.docx